ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22 август, 2022 ел № 16/9

Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 32, 36 пунктлары, Россия Федерациясе Су кодексының 27 статьясы, шәһәр Уставының 28 статьясы 2 өлеше 68 пункты нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләрен кушымтада каралган тәртиптә расларга.

2. Шәһәр Советы Карарлары көчен югалткан дип танырга:

1) «Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләрен раслау турында» 2008 елның 25 сентябрендәге 34/14 номерлы Карары, «Челнинские известия» газетасының 2008 ел, 8 октябрьдәге 195-196 саннарында басылган;

2) «Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/14 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 16 октябрендәге 33/10 номерлы Карары, «Челнинские известия» газетасының 2014 ел, 22 октябрьдәге 79 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2014 ел, 22 октябрьдәге 79 санында басылган;

3) «Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/14 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 11

августындагы 41/11 номерлы Карары, «Челнинские известия» газетасының 2020 ел, 19 августтагы 60 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2020 ел, 21 августтагы 61 санында басылган;

4) «Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/14 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 18 мартындагы 6/14 номерлы Карары, «Челнинские известия» газетасының 2021 ел, 24 марттагы 20 санында, «Шәһри Чаллы» 2021 ел, 26 марттагы 20 санында басылган;

5) «Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/14 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 13 апрелендәге 14/10 номерлы Карары, «Челнинские известия» газетасының 2022 ел, 20 апрельдәге 27 санында, «Шәһри Чаллы» 2022 ел, 20 апрельдәге 27 санында басылган;

6) «Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/14 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 23 июнендәге 15/12 номерлы Карары, «Челнинские известия» газетасының 2022 ел, 24 июньдәге 44 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2022 ел, 29 июньдәге 45 санында басылган;

3.Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
16/9 Карарына кушымта
22 август, 2022 ел.

## Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләре

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Кагыйдәләр «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану өлкәсендә шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен бердәм һәм мәҗбүри нормаларны һәм таләпләрне үтәүгә карата таләпләрне билгели.

2. Әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган төп төшенчәләр:

- су объекты – даими яки вакытлыча су тупланган сулыкның характерлы формалары һәм су режимы билгеләре булган табигый яисә ясалма сулык, су агымы яки башка объект;
- яр буе полосасы – гомуми файдаланудагы су объектының яр буе линиясе (су объекты чикләре) буендагы җир полосасы; су объектлары өчен яр буе полосасының киңлеге Россия Федерациясе Су кодексы белән билгеләнә;
- гомуми файдаланудагы су объекты – дәүләт яисә муниципаль милектәге, әгәр су законнарында башкасы каралмаган булса, һәркем файдалана алырлык су объекты булган өске су объекты;
- су саклау зонасы – су объектының яр линиясенә тоташкан территория, анда су объектларының пычрануын, чүпләнүен, сулыкларны ләм басып алуны булдырмау, шулай ук су биологик ресурсларының яшәү тирәлеген һәм хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының башка объектларының яшәү тирәлеген саклап калу максатларында хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимы билгеләнә; су объектларының су саклау зонасы киңлеге Россия Федерациясе Су кодексы белән билгеләнә;
- су объектларыннан файдалану (судан файдалану) – Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр, физик һәм юридик затлар ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен су объектларыннан төрле ысуллар белән файдалану;
- шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары – эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган шәхси, гаилә, йорт ихтыяҗлары;
- яр буен саклау полосасы – су саклау зоналары чикләрендәге хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә өстәмә чикләүләр кертелә торган территория;
- агым сулар – яңгыр сулары, кар сулары, инфильтрацион, су сендерү-юу, дренаж сулары, үзәкләштерелгән су агызу системасы сулары һәм башка сулар, аларны су объектларына чыгару (агызу) алардан файдаланганнан яисә сусаклагыч мәйданынд агып төшкәннән соң башкарыла.

## 2 бүлек. Шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалануга таләпләр

3. Һәр граждан гомуми файдаланудагы су объектларыннан бертигез файдалану хокукына ия һәм, әгәр Россия Федерациясе Су кодексында, башка федераль законнарда башкасы каралмаган булса, алардан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен түләүсез файдаланырга мөмкин.

4. Гражданнар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан ял итү, туризм, спорт, һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы, яшелчә- җимеш бакчалары җир кишәрлекләренә су сибү, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен су объектларыннан файдалануга бәйле башка максатлар өчен файдаланырга;

2) гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосасыннан хәрәкәт итү (механик транспорт чараларын кулланмыйча) һәм алар янында булу өчен, шул исәптән һәвәскәр балыкчылык өчен, һәм йөзмә чараларга причал буларак файдаланырга;

3) су законнары нигезендә гомуми судан файдалануны гамәлгә ашырырга.

5. Шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдаланганда гражданнар:

1) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нигезләрдә су объектыннан файдаланучы су кулланучыларга аларның хокукларын чикләргә, шулай ук кешеләр өчен каршылыклар һәм куркыныч тудырырга хокуклы түгел;

2) су объектларын саклау кагыйдәләрен белергә һәм үтәргә тиеш;

3) Россия Федерациясе законнарында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән гомуми судан файдалануның башка таләпләрен үтәргә тиеш.

6. Гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалануга бәйле чикләүләр Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм әлеге Кагыйдәләр нигезендә билгеләнә.

7. Юридик затлар, физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдаланганда киңлеге Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән су саклау зоналарыннан һәм яр буе саклау полосаларыннан файдалану режимын үтәргә тиеш.

8. Кече үлчәмле судноларда йөзү өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.

9. Кешенең гомеренә яисә сәламәтлегенә зыян китерү, радиация авариясе яисә табигый яисә техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерү, гидроэнергетика объектларының саклау зоналарын билгеләү куркынычы янаган очракларда, шулай ук федераль законнарда каралган башка очракларда судан файдалану Россия Федерациясе Су кодексында каралган тәртиптә туктатылырга яисә чикләнергә мөмкин.

3 бүлек. Шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен су җыюга таләпләр

10. Эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү максатларында законнарда каралган тәртиптә санитар-эпидемиологик нәтиҗәләр нигезендә күрсәтелгән максатлар өчен яраклы булган, пычранудан һәм чүпләнүдән сакланган гомуми файдаланудагы су объектлары файдаланылырга тиеш.

11. Сулыклардан файдаланучыларга зыян китерә торган күләмдә бакча, бакча җир участокларына су сибү, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шулай ук башка авыл хуҗалыгы хайваннарын карау эшләрен башкару өчен су алу тыела.

4 бүлек. Рекреация максатларында гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану

12. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми файдаланудагы су объектларыннан ял итү, су коену, спорт, шулай ук массакүләм чаралар үткәрү өчен файдалану әлеге Кагыйдәләр таләпләрен үтәп, шулай ук “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән таләпләрне үтәп рөхсәт ителә.

13. Гомуми файдаланудагы су объектларында җәйге чорда түбәндәгеләр тыела:

1) кисәтүләр һәм тыю турында махсус мәгълүмат билгеләре куелган урыннарда коену;

2) җиһазланмаган урыннарда коену;

3) катерлардан, көймәләрдән, причаллардан, шулай ук бу максатлар өчен яраксыз корылмалардан суга сикерү;

4) моторлы, җилкәнле судноларга, ишкәкле көймәләргә һәм башка йөзү чараларына йөзеп бару;

5) хәвеф турында ялганлап кычкырырга;

6) исерткеч эчемлекләр эчәргә, исерек хәлдә су коенырга;

7) сулыкларны һәм яр полосасын пычратырга һәм чүпләргә;

8) үзең белән этләр һәм башка хайваннар алып килергә;

9) кызгылт сары төстәге сигнал калкавычлары белән билгеләнгән су объекты акваториясе участогы чикләрендә гражданнарның коену урыннарына турыдан-туры якын җирдә балык тоту;

10) су объекты территориясенә механик транспорт чарасында керергә, шулай ук аны юарга

11) кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерә торган башка гамәлләр кылырга.

## 5 бүлек. Гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану Кагыйдәләре турында мәгълүмат тапшыру

14. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларында файдалану кагыйдәләре яисә судан файдалануны чикләү кагыйдәләре турында мәгълүмат бирү җирле үзидарә органнары тарафыннан массакүләм мәгълүмат чаралары (басма матбугат, телевидение, радио), Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты, махсус мәгълүмат билгеләре һәм башка ысуллар ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 6 бүлек. Әлеге Кагыйдәләрне бозган өчен җаваплылык

15. Әлеге Кагыйдәләрне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

16. Су законнарын бозган өчен җаваплылыкка җәлеп итү гаепле затларны хокук бозуны бетерү һәм алар тарафыннан китерелгән зыянны түләтүдән азат итми.